# КАРАР (РЕШЕНИЕ)

## Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге составына керүче Алан-Елга торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

23.11.2023 ел № 1

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары , 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге Уставының 23 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге Советының 17.12.2021 елның 27 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясе өлешендә) гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында " карарына таянып 2023 елның 23 ноябрендә узган гражданнар җыенында «2024 нче елда Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлегенә керүче Алан-Елга торак пунктында, яшәү урыны буенча Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлегенең Алан-Елга торак пункты составына теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,0 (Биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде һәм җыелган акчаларны конкрет тоту юнәлешенә җибәрү турында:

- Алан-Елга торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларына вак таш салып чокырларны ремонтлау (сатып алу, ташу, вак таш салу, килешү буенча эш өчен түләүләр).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган, гражданнар җыенына 219 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 114 кеше тавыш бирүдә катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 114 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1.Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге составына керүче Алан-Елга торак пунктында халык җыенын үткән дип таныргa, халык җыены нәтиҗәләре – чын мәгънәсендә дип таныргa.

2.«2024 нче елда Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлегенә керүче Алан-Елга торак пунктында, яшәү урыны буенча Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлегенең Алан-Елга торак пункты составына теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,0 (Биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә» һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге киләсе мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме? - дигән сорау буенча:

1) Алан-Елга торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларына вак таш салып чокырларны ремонтлау (сатып алу, ташу, вак таш салу, килешү буенча эш өчен түләүләр) карарын кабул ителгән дип таныргa.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/shikshi адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында
рәислек итүче,
Шекше авыл
җирлеге башлыгы

Р.Р. Хәйртдинов